**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында конкурентлыкны үстерү стандарты нигезләмәләренә таянып **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турында» 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1229 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 10 мартындагы ПУ-209 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге ПУ-800 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-152 номерлы, 2018 елның 26 маендагы ПУ-392 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге ПУ-844 номерлы һәм 2019 елның 21 февралендәге ПУ-140 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «2015 елның 5 сентябрендәге 1738-р номерлы» сүзләрен «2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия турындагы нигезләмәдә:

2 пунктта «2015 елның 5 сентябрендәге 1738-р номерлы» сүзләрен «2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

үз утырышларында түбәндәгеләрне карау:

һәр товар базарының ни өчен сайлануы дәлилле нигезләнгән һәм һәр товар базарындагы вазгыять тасвирланган, шулай ук төп проблемалар һәм аларны чишү юллары анализланган товар базарлары исемлеге проектын;

«юл картасы»нда каралган чараларны эшләү һәм аларны үтәү турындагы мәгълүматны да кертеп, конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү чаралары планы («юл картасы») проектын;

Татарстан Республикасының товар базарларында конкурентлыкның торышы һәм үсеше нәтиҗәләрен һәм мониторинг нәтиҗәләре анализын;

Комиссия әгъзаларының Татарстан Республикасында конкурентлык сәясәтен камилләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәрен;

башка мәгълүматны һәм аларның конкурентлыкның торышына һәм үсешенә йогынты ясау мөмкинлеге өлешендә Татарстан Республикасы хокукый актлары проектларын, шулай ук Татарстан Республикасында контроль-тикшерү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турындагы хисапны»;

Татарстан Республикасының товар базарларында конкурентлыкның торышы һәм үсеше турындагы еллык докладны карап тикшерү һәм раслау.»;

в) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Т.Д. Нагумановны, Б.З. Хаҗиәхмәтовны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Камалова Венера Айдар кызын – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире урынбасарын;

Синяшин Олег Герольдовичны – «Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәге директорын (килешү буенча);

Фомин Анатолий Алексеевичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 21 август
№ ПУ-478